ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында” Татарстан Республикасы Законының 5 һәм 25 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 25 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында” 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяга түбәндәге эчтәлекле $4^2$ пункт өстәргә:

“$4^2$) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы буйсынуындагы медицина оешмаларында кеше органнарын һәм тукымаларын трансплантацияләүгә (күчереп утыртуга), шул исәптән трансплантацияләү (күчереп утырту) максатларында органнарның һәм тукымаларның донорлыгына бәйле медицина эшчәнлеген оештыру;”;

2) 25 статьяга түбәндәге эчтәлекле $6^1$ пункт өстәргә:

“$6^1$) трансплантацияләү (күчереп утырту) максатларында органнарның һәм тукымаларның донорлыгына бәйле һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы буйсынуындагы медицина оешмаларына бүлеп бирү өчен каралган Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән гамәлгә ашырыла торган медицина эшчәнлеге буенча;”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2015 елның 8 октябре
№ 73-ТРЗ